ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОЗАРЕЧЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ЗАРЕЧЕНСК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Яңа Зареченск авылы

10.09.2021нче ел № 19

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы
Яңа Зареченск авыл җирлеге Башкарма комитетының
«Агач, куаклар кисүгә, кронлау, утыртуга һәм
газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында»
04.08.2021 ел №15 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге Башкарма комитетының 04.08.2021 ел №15 карары белән расланган агач, куаклар кисүгә, кронлауга, утыртуга һәм газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында "агачлар, куакларның авариясе турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацы чыгару;

1.3. пункт 2.5.4. чыгару;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яки җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.1 пунктының 6, 11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3. пунктында "Башкарма комитетның структур бүлекчәсе" сүзләрен «Муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә, һәрхәлдә (авария хәлендәге агачларны) хәлдә булуы турында  сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8.  2.8.2 пунктының 5 пунктчасында "(авария-торгызу эшләре үткәрүгә яки һәрхәлдә яшел үсентеләрне сүтүгә бәйле очраклардан тыш)" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында 2 нче кушымтада сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында шулай ук авария-торгызу эшләре үткәрү өчен яисә яшел үсентеләрне сүтү өчен яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның егылу куркынычын бетерү өчен) сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3 пункт чыгару;

1.12. 3.5.5 пунктында «мөрәҗәгать итүченең авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә һәрхәлдә яшел үсентеләрне сүтү өчен муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның егылу куркынычын бетерү өчен) – ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. регламентның 2 нче кушымтасында “авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш” чыгару.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Яңа Зареченск авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Шарифуллина